| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ЖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

02.08.2017 № 378-пр

Казан ш.

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 06.06.2017 № 254-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт вазифаларын башкару өчен зарури профессиональ белем, белгечлек һәм әзерлек юнәлеше дәрәҗәсенә квалификацион таләпләренә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге № 79–ФЗ Федераль законның 12 статьясының 1 кисәгенә, «Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы № 3-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 10 статьясындагы 1 кисәгенә туры китереп, боерам:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт вазифаларын башкару өчен зарури профессиональ белем, белгечлек һәм әзерлек юнәлеше дәрәҗәсенә квалификацион таләпләрен раслау турында» 06.06.2017 № 254-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт вазифаларын башкару өчен зарури профессиональ белем, белгечлек һәм әзерлек юнәлеше дәрәҗәсенә квалификацион таләпләрнең 62 нче юлын түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәреш кертергә:

| | | |
|---|---|---|
| "62 | Әйдәп баручы киңәшче | «Дәүләти һәм муниципаль идарә», «Икътисад һәм идарә», «Икътисад», «Менеджмент», «Региональ икътисад», «Финанслар һәм кредит», «Финанслар», |

| | | |
|---|---|---|
| | | «Юриспруденция», “Экспертиза һәм күчемсез милек белән эш итү” белгечлеге буенча югары белем яки Россия Федерациясенең мәгариф турында законнары буенча тиешле белгечлекләр (белгечлек)_ һәм әзерлек юнәлешләрендә тиешлеге билгеләнгән исемлекләрдә китерелгән башка белгечлекләр (белгечлек) яки әзерлек юнәлешләре |

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Министр
А.К.ХАМАЕВ